# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге составына керүче Уразбахты авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 1 «12» ноябрь, 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында 2020 елның «12» ноябрендә узган үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Уразбахты авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү ) Пионер урамы, Уразбахты авылы;
- Уразбахты авылы урам юлларын кардан чистарту;
- җәй көне Уразбахты авылында юлларны кырдырып тигезләү;
- Уразбахты авылында чишмәләрне төзекләндерү (сатып алу, материалларны ташу, ремонт, төзекләндерү, килешү буенча эш өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 198 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 111 кеше, 56 % тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 111 кеше тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен _ 0 _ кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлегенең Уразбахты авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге Уразбахты торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү ) Пионер урамы, Уразбахты авылы;
- Уразбахты авылы урам юлларын кардан чистарту;
- җәй көне Уразбахты авылында юлларны кырдырып тигезләү;
- Уразбахты авылында чишмәләрне төзекләндерү (сатып алу, материалларны ташу, ремонт, төзекләндерү, килешү буенча эш өчен түләү);

3. Әлеге карарны Уразбахты авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уразбахты авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Уразбахты авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе

Р.Г.Шәйхетдинов